# *Татар теле дәресе. 3 нче сыйныф.*

Максат:

- Сыйфат турында алган белемнәрне ныгыту.
- Антоним сыйфатлар турындагы белемнәрне арттыру.
- Мөстәкыйль эшләү, логик фикер йөртү,

чиста - пөхтә эшләү күнекмәләрен үстерү.

Унсигезенче февраль.

Сыйныф эше.

*Уу / уу / Уу / уу*

*матур, сылу, алсу йөзле, алтын куллы*

# Сыйфат

Предметның **билгесен** белдерә.

**Нинди? Кайсы?** сорауларына җавап бирә.

**Сыйфатлар исемгә** бәйләнеп килә.

**Сыйфатлар** сөйләмне матурлыйлар. Алар предметларны, күренешләрне төрле яктан сурәтлиләр.

**Сыйфатлар** предметларның ***төрле билгеләрен*** белдерәләр:

- **төсне:** *ак, сары, кара, яшел, кызыл;*
- **тәмне:** *ачы, төче, татлы, баллы, тозлы;*
- **форманы:** *озын, түгәрәк, кәкре, кыска;*
- **холыкны:** *көләч, усал, юаш, шаян, сизгер, куркак, кыю, батыр, хәйләкәр, ерткыч;*
- **вакытны:** *кышкы, җәйге, кичке, иртәнге,быелгы;*
- **Табигать күренешләренең билгеләрен:** *буранлы, яңгырлы, җилле, җиләс, аяз, болытлы;*

# Сыйфатларны кем табар?

Ал шар оча.

Яшел шар оча.

Түгәрәк шар очты.

Миңа зур шар алдылар.

# Тест

1. Сыйфатлар нәрсә белдерә ?

**а) предметны; б) предметның эшен; в) предметның билгесен;**

2. Сыйфатларга нинди сораулар куела ?

**а) кем? нәрсә?; б) нинди? кайсы?; в) нишли? нишләде?;**

3. Сыйфатлар нәрсәгә бәйләнеп килә ?

**а) исемгә; б) фигыльгә; в) кисәкчәләргә;**

4. ***Уңган*** сүзенә **синоним сыйфат** табыгыз:

**а) ялкау; б) шаян; в) өлгер;**

5. ***Салкын*** сүзенә **антоним сыйфат** табыгыз:

**а) кызыл; б) җылы; в) җәйге;**

# Тестның җаваплары

1. **в) предметның билгесен;**
2. **б) нинди? кайсы?;**
3. **а) исемгә;**
4. **в) өлгер;**
5. **б) җылы;**

# Антоним сыйфатлар

- җылы
- ак
- тирән
- каты
- яшь
- караңгы
- начар
- ахмак
- ерак

- карт
- якты
- йомшак
- акыллы
- яхшы
- якын
- кара
- сай
- салкын

# Укыгыз. Тиешле антоним сыйфатларны куеп языгыз.

**Җир … , кар … .**

**Җәй … , кыш … .**

**Диңгез … , инеш … .**

**Таш … , мамык … .**

*Үрнәк:* ***Җир кара, кар ак.***

**Сыйфатлар:** *җылы, кара, тирән, каты, салкын, ак, сай, йомшак.*

# Физкультминут



# Антонимнары белән парлап языгыз.

матур - …, ямьле - …, акыллы - …, бай - …, караңгы - …, чиста - …, яшь - …, җиңел - …, яңа - …, төз - …, куе - …, ачы - …, ерак - …

**Өзекне чагыштырып укыгыз. Кайсы өзек тулырак, матурраак тоела?**

Тагын яз җитте. Яңгырлар явып үтте. Агачлар яфракларга күмелде. Шомырт чәчәк ата. Өй кыекларында сыерчыклар җилпенә. Һавада тургай сайрый, умарта кортлары, чәчәкләргә чумып, бал җыя.

Бер – ике атна үтәр, чәчәкләр коелыр, алар урынына җимешләр күренә башлар.

Тагын кояшлы ямьле яз җитте. Беренче җылы яңгырлар явып үтте. Агачлар ямь-яшел яфракларга күмелделәр. Шомырт ак чәчәк ата. Өй кыекларында дәртле сыерчыклар җилпенә, һавада моңлы тургай сайрый, умарта кортлары, хуш исле чәчәкләргә чумып, тәмле бал җыялар.

Бер – ике атна үтәр, матур чәчәкләр коелыр, алар урынына яшел җимешләр күренә башлар.

***Сыйфат сөйләмдә ни өчен кирәк?***
***Сыйфатларны үзләре бәйләнгән исемнәр белән күчереп языгыз.***
***Сыйфатларның асларына сызыгыз.***

***Сыйфат сөйләмдә ни өчен кирәк?***

Сыйфатлар сөйләмне матурлыйлар.

Алар предметларны, күренешләрне төрле яктан сурәтлиләр.

## *Сыйфатларны кем табар?*

**Көләч, ачык, якты** йөзле,
**Тәмле, йомшак, җылы** сүзле
Әнием – иң **якын** кешем,
Бик остасы һәрбер эшнең.

*(Нажия Саттарова)*

Өй эше: *230 нчы күнегү.*

# Мәкальләрнең мәгънәләрен аңлат.

**Акылы кысканың теле … .**

**Яңа дустым булды дип, … дусны ташлама.**

**Бауның озыны, сүзнең … яхшы.**

**… телне кадерләгән халык кадерле булыр.**

# Йомгаклау.

Укучылар, бу дәрес сезгә ошадымы?

Бу дәрестә безниләр эшләдек?

Сыйфат дип нинди сүзләр атала?

Аларга нинди сораулар куела?

Сыйфатлар ни өчен кулланыла?